УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

02.12.2014№01-05/263-пр

Казан шәһәре

«Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең тракторларны, үзйөрешле юллар салу машиналарын, бүтән машиналарны һәм аларга тагылмаларны залогка салуны теркәү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентын раслау турында» 24.06.2013 № 01-05/97-пр боерыгының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясе Граждан кодексының I өлешенә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2013 елның 21 декабрендәге 367-ФЗ номерлы Федераль законны кабул итүгә бәйле рәвештә

**БОЕРЫК БИРӘМ**:

1. «Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең тракторларны, үзйөрешле юллар салу машиналарын, бүтән машиналарны һәм аларга тагылмаларны залогка салуны теркәү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 24.06.2013 № 01-05/97-пр боерыгының үз көчен югалтуын танырга.
2. Теркәү, автоматлаштырылган исәпкә алу һәм махсус эш бүлеге секторы (М.Ш.Аймалетдинов) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе сайтындагы «Дәүләт хезмәт күрсәтүләре» бүлегенең «Административ регламентлар» бүлекчәсендә урнаштырырга тиеш.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Р.Р. Зыятдинов